**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О квотировании и резервировании рабочих мест для инвалидов и граждан, особо нуждающихся в социальной защите»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
11 июля 2024 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 24 июля 2006 года № 60-ЗРТ «О квотировании и резервировании рабочих мест для инвалидов и граждан, особо нуждающихся в социальной защите» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2006, № 7 (I часть); 2012, № 7 (I часть); 2013, № 7; 2014, № 6 (I часть), № 6 (II часть), № 12 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2019, № 2 (часть I); 2021, № 93 (часть I); 2022, № 57 (часть I) следующие изменения:

1) наименование изложить в следующей редакции:
«**О квотировании рабочих мест для приема на работу инвалидов и резервировании отдельных видов работ (профессий) для трудоустройства инвалидов и граждан, особо нуждающихся в социальной защите**»;

2) преамбулу признать утратившей силу;

3) статью 1 изложить в следующей редакции:
«Статья 1. **Законодательство о квотировании рабочих мест для приема на работу инвалидов и резервировании отдельных видов работ (профессий) для трудоустройства инвалидов и граждан, особо нуждающихся в социальной защите**

Законодательство о квотировании рабочих мест для приема на работу инвалидов и резервировании отдельных видов работ (профессий) для трудоустройства инвалидов и граждан, особо нуждающихся в социальной защите, основывается на соответствующих положениях Конституции Российской

Федерации, Конституции Республики Татарстан и состоит из федеральных законов и иных нормативных правовых актов Российской Федерации, законов Республики Татарстан и иных нормативных правовых актов Республики Татарстан.»;

4) в пункте 3 статьи 2:

а) абзац седьмой после слов «многодетные родители,» дополнить словами «усыновители, опекуны (попечители),»;

б) в абзаце восьмом слова «чернобыльской и других» исключить;

в) абзац девятый дополнить словами «(в случае прохождения указанными гражданами в данный период военной службы по призыву – с даты окончания прохождения военной службы по призыву)»;

г) абзац двенадцатый дополнить словами «, и ищущие работу в течение одного года с даты освобождения»;

5) в статье 3:

а) часть 1 изложить в следующей редакции:

«1. Квота для приема на работу инвалидов устанавливается для работодателей, осуществляющих деятельность на территории Республики Татарстан, в процентах от среднесписочной численности работников в соответствии с методическими рекомендациями, утверждаемыми федеральным органом исполнительной власти, осуществляющим функции по выработке и реализации государственной политики и нормативно-правовому регулированию в сфере занятости населения, в следующих размерах:

1) для работодателей, численность работников которых составляет от 35 человек до 100 человек включительно, – в размере 2 процентов;

2) для работодателей, численность работников которых превышает 100 человек, – в размере 3 процентов.

Размер квоты для приема на работу инвалидов для различных видов экономической деятельности, различных муниципальных образований Республики Татарстан не дифференцируется.»;

б) часть $1^1$ после слов «среднесписочной численности работников» дополнить словами «за предыдущий квартал»;

в) часть $1^2$ дополнить словами «за предыдущий квартал»;

г) часть 2 изложить в следующей редакции:

«2. Освобождаются от выполнения установленной квоты для приема на работу инвалидов работодатели:

1) в случае, если они являются общественными объединениями инвалидов;

2) в иных случаях, установленных Правительством Российской Федерации.»;

д) часть 3 признать утратившей силу;

е) части 11 и 12 изложить в следующей редакции:

«11. Выполнение работодателем установленной квоты для приема на работу инвалидов обеспечивается в соответствии с порядком, установленным Правительством Российской Федерации:

1) в случае заключения трудового договора с инвалидом на рабочее место непосредственно у работодателя;

2) в случае заключения трудового договора между инвалидом и организацией, включая общественные объединения инвалидов и образованные ими организации, в том числе хозяйственные товарищества и общества, уставный (складочный) капитал которых состоит из вклада общественного объединения инвалидов (далее – иная организация), или индивидуальным предпринимателем в соответствии с соглашением о трудоустройстве инвалидов, заключаемым между работодателем, которому установлена квота для приема на работу инвалидов, и иной организацией или индивидуальным предпринимателем;

3) в иных случаях, установленных Правительством Российской Федерации.

12. Трудоустройство инвалидов в соответствии с соглашением о трудоустройстве инвалидов, предусмотренным пунктом 2 части 11 настоящей статьи, должно осуществляться на территории Республики Татарстан по месту нахождения работодателя (его представительства, филиала).»;

6) статью 4 изложить в следующей редакции:

«Статья 4. **Резервирование отдельных видов работ (профессий) для трудоустройства инвалидов**

1. У работодателей, за исключением указанных в части 2 статьи 3 настоящего Закона, осуществляется резервирование отдельных видов работ (профессий), наиболее подходящих для трудоустройства инвалидов.

2. Резервирование отдельных видов работ (профессий), наиболее подходящих для трудоустройства инвалидов, осуществляется в порядке, определяемом Кабинетом Министров Республики Татарстан.»;

7) в статье 5:

а) в наименовании слова «рабочих мест» заменить словами «отдельных видов работ (профессий)»;

б) часть 1 изложить в следующей редакции:

«1. Работодателями резервируются отдельные виды работ (профессий) для трудоустройства граждан, особо нуждающихся в социальной защите, определяемые уполномоченным органом исполнительной власти Республики Татарстан в области труда и занятости.»;

в) в части 2 слова «резервируемых рабочих мест» заменить словами «рабочих мест по резервируемым отдельным видам работ (профессий)», слова «в частях 2 и 3» заменить словами «в части 2»;

г) в части 3 слова «рабочих мест» заменить словами «отдельных видов работ (профессий)»;

8) в статье 6:

а) пункт 2 части 1 изложить в следующей редакции:

«2) трудоустраивать инвалидов на рабочие места у других работодателей в счет установленных квот для приема на работу инвалидов в соответствии с соглашением, заключаемым с иной организацией или индивидуальным предпринимателем;»;

б) часть 2 изложить в следующей редакции:

«2. Работодатели обязаны:

1) выполнить квоту для приема на работу инвалидов, резервировать отдельные виды работ (профессий) для трудоустройства инвалидов и граждан, особо нуждающихся в социальной защите;

2) принимать локальные нормативные акты, содержащие сведения:

о создаваемых или выделяемых рабочих местах для трудоустройства инвалидов;

о резервируемых отдельных видах работ (профессий) для трудоустройства инвалидов и граждан, особо нуждающихся в социальной защите;

3) ежемесячно информировать органы службы занятости Республики Татарстан посредством размещения информации о выполнении квоты для приема на работу инвалидов на единой цифровой платформе или на иных информационных ресурсах, на которых может размещаться такая информация в соответствии с порядком, утвержденным Правительством Российской Федерации;

4) создавать инвалидам условия труда в соответствии с индивидуальной программой реабилитации или абилитации инвалида.»;

9) в статье 7:

а) в части 1 слова «резервируемых рабочих мест» заменить словами «рабочих мест по резервируемым отдельным видам работ (профессий)»;

б) в части 2 слова «резервируемых рабочих мест» заменить словами «рабочих мест по резервируемым отдельным видам работ (профессий)»;

10) в статье 8 слова «квотированию и резервированию рабочих мест для инвалидов и» заменить словами «квотированию рабочих мест для приема на работу инвалидов и резервированию отдельных видов работ (профессий) для трудоустройства инвалидов и».

**Статья 2**

1. Настоящий Закон вступает в силу с 1 сентября 2024 года, за исключением пункта 4 статьи 1 настоящего Закона.

2. Пункт 4 статьи 1 настоящего Закона вступает в силу с 1 января 2025 года.

Глава (Раис)
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
26 июля 2024 года
№ 63-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 11 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 7 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 7; 2014, № 6 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 2 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«**Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау хакында**»;

2) преамбуланы үз көчен югалткан дип танырга;

3) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1 статья. **Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау турындагы законнар**

Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау турындагы законнар Россия Федерациясе

Конституциясенең, Татарстан Республикасы Конституциясенең тиешле нигезләмәләренә нигезләнә һәм федераль законнардан һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларыннан, Татарстан Республикасы законнарыннан һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актларыннан тора.»;

4) 2 статьяның 3 пунктында:

а) җиденче абзацта «күп балалы ата-аналар» сүзләреннән соң «, уллыкка (кызлыкка) алучылар, опекуннар (попечительләр)» сүзләрен өстәргә;

б) сигезенче абзацта «Чернобыль һәм башка» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) тугызынчы абзацта «(әлеге гражданнар шушы чорда чакырылыш буенча хәрби хезмәт үткән очракта – чакырылыш буенча хәрби хезмәт үтү тәмамланган датадан алып)» сүзләрен өстәргә;

г) уникенче абзацка «кайткан» сүзеннән соң «һәм азат ителү датасыннан алып бер ел дәвамында эш эзләүче» сүзләрен өстәргә;

5) 3 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Инвалидларны эшкә алу өчен квота эшчәнлеге Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыручы эш бирүчеләр өчен федераль башкарма хакимиятнең халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм башкару һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы органы тарафыннан раслана торган методик тәкъдимнәр нигезендә хезмәткәрләрнең исемлектәге уртача саныннан процентларда түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

1) хезмәткәрләренең саны 35 кешедән алып 100 кешегә кадәр булган, 100 кешене кертеп, эш бирүчеләргә – 2 процент күләмендә;

2) хезмәткәрләренең саны 100 кешедән артык булган эш бирүчеләргә – 3 процент күләмендә.

Икътисадый эшчәнлекнең төрле төрләре, Татарстан Республикасының төрле муниципаль берәмлекләре өчен инвалидларны эшкә алу өчен квота күләме дифференциацияләнми.»;

б) $1^1$ өлештә «исәпкә алмыйча,» сүзләреннән соң «алдагы кварталга» сүзләрен өстәргә;

в) $1^2$ өлештә «квота,» сүзеннән соң «алдагы кварталга» сүзләрен өстәргә;

г) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квотаны үтәүдән эш бирүчеләр түбәндәге очракларда азат ителә:

1) әгәр алар инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре булса;

2) Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән башка очракларда.»;

д) 3 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

е) 11 һәм 12 өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квотаны эш бирүче тарафыннан үтәү Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртип нигезендә түбәндәге очракларда тәэмин ителә:

1) инвалид белән турыдан-туры эш бирүчедә эш урынына хезмәт шартнамәсе төзелгәндә;

2) инвалидларны эшкә алу өчен квота билгеләнгән эш бирүче һәм оешма, инвалидларның иҗтимагый берләшмәләрен һәм алар төзегән оешмаларны да кертеп, шул исәптән устав (җыелма) капиталы инвалидларның иҗтимагый берләшмәсе кертеменнән торган хуҗалык итү ширкәтләре һәм җәмгыятьләре (алга таба – башка оешма), яисә индивидуаль эшкуар арасында төзелә торган инвалидларны эшкә урнаштыру турындагы килешү нигезендә инвалид һәм башка оешма яисә индивидуаль эшкуар арасында хезмәт килешүе төзелгәндә;

3) Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән башка очракларда.

12. Әлеге статьяның 11 өлешендәге 2 пунктында каралган инвалидларны эшкә урнаштыру турындагы килешү нигезендә инвалидларны эшкә урнаштыру Татарстан Республикасы территориясендә эш бирүченең (аның вәкиллегенең, филиалының) урнашу урыны буенча гамәлгә ашырылырга тиеш.»;

6) 4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 статья. **Инвалидларны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау**

1. Эш бирүчеләрдә, әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгәннәреннән тыш, инвалидларны эшкә урнаштыру өчен аеруча уңайлы булган аерым эш төрләре (һөнәрләр) резервлана.

2. Инвалидларны эшкә урнаштыру өчен аеруча уңайлы булган аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

7) 5 статьяда:

а) исемдә «эш урыннары» сүзләрен «аерым эш төрләрен (һөнәрләрне)» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган аерым эш төрләре (һөнәрләр) эш бирүчеләр тарафыннан резервлана.»;

в) 2 өлештә «резервланучы эш урыннары» сүзләрен «резервлана торган аерым эш төрләре (һөнәрләр) буенча эш урыннары» сүзләренә алмаштырырга, «2 һәм 3 өлешләрендә» сүзләрен «2 өлештә» сүзләренә алмаштырырга;

г) 3 өлештә «эш урыннары» сүзләрен «аерым эш төрләрен (һөнәрләрне)» сүзләренә алмаштырырга;

8) 6 статьяда:

а) 1 өлешнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) инвалидларны башка оешма яисә индивидуаль эшкуар белән төзелә торган килешү нигезендә инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квоталар исәбеннән башка эш бирүчеләрдәге эш урыннарына эшкә урнаштырырга;»;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Эш бирүчеләр түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) инвалидларны эшкә алу өчен квотаны үтәргә, инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервларга;

2) түбәндәгеләр турында белешмәләр булган локаль норматив актлар кабул итәргә:

инвалидларны эшкә урнаштыру өчен булдырыла яисә бүлеп бирелә торган эш урыннары;

инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен резервлана торган аерым эш төрләре (һөнәрләр);

3) ай саен Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына бердәм цифрлы платформада яисә инвалидларны эшкә кабул итү квотасы үтәлеше турындагы мәгълүмат Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган тәртип нигезендә урнаштырыла ала торган башка мәгълүмат ресурсларында мондый мәгълүматны урнаштыру аша хәбәр итәргә;

4) инвалидны реабилитацияләүнең яисә абилитацияләүнең индивидуаль программасы нигезендә инвалидларга хезмәт шартлары булдырырга.»;

9) 7 статьяда:

а) 1 өлештә «резервланучы эш урыннары» сүзләрен «резервлана торган аерым эш төрләре (һөнәрләр) буенча эш урыннары» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «резервланучы эш урыннары» сүзләрен «резервлана торган аерым эш төрләре (һөнәрләр) буенча эш урыннары» сүзләренә алмаштырырга;

10) 8 статьяда «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау» сүзләрен «Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пунктыннан тыш, 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пункты 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 26 июль
№ 63-ТРЗ